РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 декабрь г.Бугульма № 1465

**2017-2019 елларга Бөгелмә муниципаль районының мәгълүматлаштыру муниципаль программасын раслау турында**

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149 номерлы Федераль законны, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152 номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында:

1. 2017-2019 елларга Бөгелмә муниципаль районының мәгълүматлаштыру муниципаль программасын расларга.

2. Финанс бюджет палатасына Бөгелмә муниципаль районы бюджетында бу максатларга тиешле финанс елына каралган бюджет шартлары нигезендә, әлеге программага кертелгән чараларны финанслауны тормышка ашырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш мәсьәләләре буенча урынбасары М. Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Галиуллин